**Байбулатова Л.**
**Р.Фәхреддин: “Сынган күңелемә вә янган йөрәгемә юаныч...”**
**// Гасырлар авазы - Эхо веков, 2001, №3-4.**

Бөек галим һәм әдип, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе, дин белгече фазыйль Ризаэддин бине Фәхреддин үзеннән соң төрле өлкәләргә караган гаять бай мирас калдырган. “Асар” (“Эзләр” яки “Истәлекләр”) дип исемләнгән зур күләмле био—библиографик хезмәт шул мирасның бер энҗеседер. Авторның ярты гомерен алган бу олуг әсәр, кызганычка каршы, тулысы белән басылмаган. Аның 1 нче һәм 2 нче томнары аерым-аерым кисәкләрдә (җөзьәләрдә) дөнья күргән булсалар да, 3 нче һәм 4 нче томнары әле дә кульъязма хәлендә ята бирәләр.

Беренче һәм икенче томнарга XIX гасыр ахырына кадәр үлгән шәхесләрнең тормышлары тасвирланган булса, өченче томда исә, XIX гасыр ахыры - XX гасыр башларында вафат булган кешеләрнең тәрҗемәи хәлләре язылган, шулар арасында Р.Фәхреддиннең үз чордашлары, гасырдашларының да биографияләре күзәтелә. Ә дүртенче җилдтә инде әүвәлге өч томнарга кермәгән яки тулыландырылган тәрҗемәи хәлләр урын алган.

“Асар”ның беренче җөзьэсе Казанда 1900 елда университет нәшриятында басылып чыккан. Ләкин әлеге җөзьәнең мөкаддимәсе укучы игътибарына беркадәре кыскартылган вариантта ирешкән иде. Мөкаддимәнең иң мөһим юллары, рус дәүләтенә, халкына зарар китерә дип, ул вакытта “мәшһүр” булган цензор В.Д.Смирнов тарафыннан кызыл кара белән сызылган. Шул юлларны укучыларга яңадан ирештерү өчен мәкалә язылган иде (“Изъятые страницы из свода “Асар” Р.Фахреддинова”, Р.Фәхреддиннең 140 еллык юбилее уңаеннан уздырылган конференция материаллары. Җыентык басмага әзерләнә).

Өченче том 1911 елда язылып беткән иде, ләкин аңа дөнья күрергә насыйп булмаган. Беренчедән, ул язылып бетсә дә, аны бастырырга материаль яктан мөмкинлек булмаганлыктан, Р.Фәхреддин акчаны бурычка алып торырга мәҗбүр булган. Икенчедән, акчасы табылса да, типографиягә алып барасы көн алдыннан 1911 елның 12 нче февралендә Фәхреддиннәр фатирында тентү вакытында жандармнар күп кенә кульъязмаларны, шул исәптән “Асар”ның өченче томын да алып киткәннәр. Әсәр авторына бары тик бер елдан соң гына кайткан, әмма китапны бастырырга мөмкинлек беткән булган инде, матди мөмкинлекләре булган кешеләр арасында да китапны бастырырга теләүчеләр күренмәгән.

Ләкин Р.Фәхреддиннең алдагы эшләреннән күренгәнчә ки, өмете тәмам өзелмәгән булган икән. Галим “Асар”ның дүртенче томын язуга керешә. Әлеге җилднең мөкаддимәсеннән аңлашылганча, аны капма-каршы уй-хисләр биләп алган. Менә аның сүзләре: “Асар”ны башлап язарга керешкән вакытымдагы әмәлләрем вә өмидләрем берлә бу көнге әхвәль вә булган эшләр арасында булган каршылык вә аерымлыкны тәгърифь итүгә көчем юк. Шул вакыттагы өмидем җир берлә күк арасында сыймас дәрәҗәсендә олуг булган. Шул өмиднең ялгыз бер хыялдан гыйбарәт икәнлеген соңгы вакытта үз күзем берлә күрдем. Дөрест, бу көндә дә бер өмидем бар. Ләкин бу өмид элек заманда булган өмидкә бөтенләй башка бер нәрсә”. Автор инде үзенең китабын укучылар табылыр дип уйламый да, үзе язганча, аның максаты да икенче төрле, беренче җилдләргә кертелмичә калган яисә кыскартылган тәрҗемәи хәлләрне яңадан тулысы белән әсәренә кертү генә.

1929 елда Ризаэддин Фәхреддин “Асар”ны икенче мәртәбә төзергә тотынган. “Ләкин беренче мәртәбәдә язарга керешкән вакытымда булган хәлем берлә бу көндәге хәлем арасында булган аерымлык мәшрикъ берлә мәгъриб арасында булган аерымлыктан да ерак”, – дип язган автор. Нәрсәгә дә булса өметләнергә мөмкинлек булган вакытта, аның “зәгыйфь” хезмәтенең халкы өчен файдалы булуын вә милләтен көчле итеп дөнья халкына күрсәтүен теләгән иде. Хәзер инде әсәрен халык өчен түгел, бәлки сынган күңеленә һәм янган йөрәгенә юаныч табу өчен генә язган. Элек булган теләкләре, максатлары, фикерләре эзсез югалган, “газиз милләте күз алдында җан биреп яткан вакытта”, “Асар”ның икенче тапкыр язылуы тарихчының яраланган җанына, тирәндә яшеренгән өмет чаткысына дәва сыман булып торган.

“Асар”ның төрле томнары өчен төрле елларда язылган “керешләрне” яңадан бастыру, аларны җентекләп өйрәнү Р.Фәхреддин карашларын хәрәкәттә, эволюциядә аңларга ярдәм итәчәк, шул исәптән бу язмада укучыларга “Асар”ның басылмаган өченче, дүртенче һәм 1929 елда яңадан язган беренче томның мөкаддимәләре имлясы беркадәре җиңелләштерелгән рәвештә

тәкъдим ителә.

**Өченче җилд "Асар" мөкаддимәсе**

Тарих белүдән мәкъсуд[1], иҗтимагый хәлләрне ислах итү[2] вә үткән эшләрдән гыйбрәт алып, киләчәкләрне өйрәнеп торудыр. Өммәтләр вә милләтләрнең һәр хосусда[3] булган тәрәккъыйләре[4], шәһәрләре үсү вә мәмләкәтләре киңәю берлә түгел, бәлки аерым фәрдләрнең[5] фикерләре киңәю вә ихаталы булу[6] берлә үлчәнер. Хәят сугышындагы галибиять[7], өстенлек аңлары вә фикерләре үсү вә алга китү берлә булыр.

Фикерләре тәрбия ителмәгән вә хәят кагыйдәләреннән вә кабер ташларыннан аермалары булмас. Бу мәгълүм бер мәсьәләдер. Мәгълүм нәрсә өчен дәлил китерү һәбәс[8] булыр.

Иҗтимагый хәлләре ислах ителгән кавемнәрнең фикерләре тәрәккъый итәр, әхлаклары төзәлер, фәрдләре арасында мәхәббәт вә хәер хаһлык[9] хөкем сөрер вә ошбу сәбәптән монларга читләр тәгадди кылмаслар[10]. Әгәр дә тәгадди кылынса, ул вакыт монлар үз хакларыны таләп итү хакында чара табудан гаҗиз[11] калмаслар.

Шушы рәвештә булган милләтләрнең фәрдләре кирәк күп вә кирәк аз булсын "олуг милләт" исемен алырга мөстәхикъ[12] булырлар вә араларыннан да җәмәгать хезмәтләре кылучы вә дөньяга файда китерүче адәмнәр заһир булыр[13]. "Олуг адәмнәр олуг милләтләрдә заһир бүлыр" димәктән морад[14], фәрдләрнең күплеге кебек хисси олуглык түгел, бәлки фикер олуглыгы вә уяу булудыр.

Иҗтимагый хәлләрне ислах кылуның бердәнбер юлы, иң зурларыннан башлап иң олугларына кадәр иҗтимагый хәлләрне интикад кылуга[15] багланадыр. Хәстәлек беленмәсә, аның хакында күрелгән тәдбирләрдән[16]вә бирелгән дәвалардан файда булмас. Хәстәлекне сөйләү гаеп түгел, бәлки аны яшерү гаептер.

Ошбуның өчен соң вакытларда язылган гомуми вә хосусый тарихларда иҗтимагый хәлләр мөмкин кадәр дөрест тәгъриф ителенә[17] вә маҗараларда[18] хәрефкә хәреф диярлек дәрәҗәдә дөрест сөйләнәдер.

Тарих язучыларның дуст-дошманнары булыр вә бәгъзы вакыт каләмнәре дә яңлышыр, ихтимал ки кайсы чакта акны кара вә караны ак кылып та язарлар. Ләкин "тарих"ның дуст-дошманы юктыр. Аның өчен бөтен халык вә бөтен мәмләкәт мөсавидыр[19]. "Тарих"ның тоткан юлы "хаклык"тан гыйбарәт булып, шуннан читкә чыкмас вә ике кешегә ике төрле күз берлә карамас. "Тарих" һичнәрсәне яшермәс, юкны бар вә барны юк итмәс, яңлышылмас. Бу да мәгълүм.

Сәләф[20] тарихчыларыннан Табари вә Бәлазури, Мәсгуди вә Фәхри, Ибнел -Әсир вә гайреләр, үзләренең вазифаларыны җиренә китерү өчен хәтта сахабәләр арасында (бәндәчелек берлә) булган мөшаҗәрә[21] вә маҗараларны да яздылар. Әгәр дә бу галимнәр яшерү касды[22] берлә бәгъзы бер нәрсәләрне бөтеләй язмаган вә яки бәгъзы урыннарда үзгәртеп сөйләгән булсалар иде "тарих"ны бозган вә үз вазифаларына җинаять иткән булырлар иде. Тарихлары бозылган кавемнәрнең дөньяда яшәгәннәре юктыр.

Шуның өчен тарихны яшерү вә яки тарафдарлык берлә язуларның зарарлы нәтиҗәләре дөрест сөйләүдән хасыйл булган[23] зарарлардан артык вә дәһшәтле булачактыр. Бу да мәгълүм.

Ибнел-Әсир вә Табари һәм дә башкалар хакларында: "Тарихларында хөрмәтле сахабәләрнең хадисәләрене[24] вә араларында булган сәяси низагларны язып хата кылдылар" диючеләрнең башлары гарешгә[25] җитеп торса да торыр, әмма шушы сүзләре хаксыз вә хөкемнәре сатхидыр[26]. Монлар "медаль"нең бер ягыны күреп тә, икенче ягыннан тәмам гафил адәмнәрдер. Шәригатьне тәблигъ[27] вакытында яшерү ярамаса, тарихи вакыйгаларны яшерү дә дөрест булмас.

Мәүзугъ[28] вә гаясен[29] ригаять итеп[30] язучы вә сөйләүче мөәррихләрне[31]мәдәният, гакыл вә гадаләт[32] һәртөрле әдәби мәсьүлиятеннән[33] азат итмештер.

Өмәвиләрнең[34] истибдадләрен[35], Габбасиларның сәфаһәтләрен[36] яшерми язучы мөәррихләрне гавам[37] фикерле салкын суфилар мөахәзә кылсалар да[38], җитди галимнәр вә мәйдан тотучы мөтәфәккирләр[39] һәр заманда шундый мөәррихләрне мөдафәга итәләр[40] вә анлар тарафында булалар.

Һәрбер косурлыктан күз йомылып та ялңыз мәдех[41] хәбәрләре генә язылган китапларны укырга һәвәс итүчеләр[42], тарих китаплары түгел "Мәнакыйбе әүлия[43]" китаплары укысыннар.

Хыял дөньясында вә “мисал” дөньясында гына булуы мөмкин булган хәбәрләнең һәрбере мондый әсәрләрдә тулыдыр.

“Асар” мәнакыйб китабы түгел, бәлки тарих мәәхәзе[44] булсын өчен тәртип ителгән хосусый тәраҗим[45] китабыдыр. Шуның өчен монда хәварикъ[46] вә кәрамәт[47] хәбәрләре, төшләр вә анларның тәгъбирләре[48] (бер сәбәпкә мәҗбур булып язылган ике-өч матдә чыгарма) булмас. Мәсьүлиятьләре равиләргә[49] гаид булып[50], хәбәрләр мөмкин кадәр тәфтиш вә дикъкать берлә нәкыл ителәләр[51].

Без һәрбер язганыбызның дөрест булачагыны дәгъва итмибез. Шулай булса да, ишеткән хәбәрләребезнең дөрестләрене табу хакында иҗтиһад[52] сарыф иттек. Касдый сурәттә[53] ифрат вә тәфрыйт кылмадык[54].

Күп төрле адәмнәр тарафыннан, бер-беренә хилаф[55] рәвештә язылган мәктүбләр вә хәбәрләрдән берәмләп җыелган сүзләр вә җөмләләрнең тәртипләрендә кимчелекләр булачагы табигыйдыр. Бу эш һәркемнән элек үзебезгә мәгълүм. Шуның өчен яңлышларым күрелсә, шунларны тасхих итеп[56], бер сүзнең хаталыгыны күрсәтер, хәтта дәлилне дә белдерер өчен өч тиенлек ачык мәктүб кяфидыр[57]. Касды дөрест булган адәм җиде тиенлек ябык мәктүб язудан да кире тормас.

Бәгъзы бер тәрҗемәләр дүрт-биш төрле мәктүбләрдән вә төрле адәмнәрдән сорашылып ишетелгән сүзләрдән хөласа[58] ясалып язылды. Шуның өчен мәктүб сахиблары яки риваять итүчеләр, язылган мәгълүматның үз риваятьләренә яки язуларына башкарак булуыны күрсәләр, моны үзләре ифадә иткән[59] нәрсәләрнең тәхриф ителүенә[60], тәгайер кылынуына[61] хәмлә итмәсеннәр[62]. Анлар хәбәрләренә хилаф булган урыннар башкалардан истифадә ителгән[63] вә нинди дәлилләргә күрә булса да, тәрҗих кылынган[64] нәрсәләр булачактыр. Әгәр дә һәр кешенең хәбәре үз мәктүбеннән күчерелсә вә яки үз гыйбарәте берлә күчерелсә, китапның бик озынаю лязем киләчәктер. Хәлбуки, табыг иттерү[65] ноктасыннан китапның озын булуы матлуб[66] түгелдер. Ошбу сәбәптән безләр гонван[67] вә ләкабләрне[68], мөстәдрик[69] вә гатыфе[70] тәфсир рәвешендәге сүзләрне моннан күп заманалар элек ташладык. Инша фәнендәге әсәрләрдә гыйбарәләрнең гүзәл вә ләззәтле булуы ни кадәр матлуб булса, тарих фәнендә язылган китапларның да мөмкин кадәр җитди вә ачык булуы матлубдыр.

Гасырдашларның бер—беренә язган мәктүбләре шул гасырның иҗтимагый вә әдәби хәлләрене күрсәтә торган көзгеләр, фикерләрне вә гая әмәлләрне үлчәргә махсус булган гадел мизаннардыр[71]. Хәтта иң мәгънәсез хисап ителгән бәгъзы бер мәктүбләрдән, шуны язган вә шуңа язылган кешеләрнең үзләре хакында гына түгел, бәлки шул заманда гореф вә гадәтләр хакында да иҗмали[72] сурәттә генә булса да, бер фикер хасыйл итмәк мөмкин буладыр. Шуның өчен безләр бәгъзы бер тәрҗемәи хәлләрдә хосусый мәктүбләрне (әдәп вә тәрбиягә хилаф яхуд[73] үз заманабызга нисбәт берлә дә сер тотылырга лязем булган матдә булмаса) тәмам яки ихтисар[74] берлә күчердек.

Күз уңымызда булган иске мәктүбләрнең йөз дә туксан бише ай хакында, рүзә вә гайд[75] низаглары хосусындадыр. Иске галимнәребез арасындагы гадавәтләрнең[76] баш сәбәбе вә ислам җәмәгатенең фиркаләргә[77] аерылуының мәншае[78] (шушы иске мәктүбләрдән аңлавымызга күрә) ошбу “ай” мәсьәләседер. Шуның өчен безләр мондый мәктүбләрдән ялңыз мисал күрсәтер өчен өч-биш гадәд[79] кадәр генә күчереп, башкаларны язарга лөзүм күрмәдек. Һиҗрәттән бишенче-алтынчы гасырлардан соң гыйлем мөтәтаффилләре[80] вә мөәллиф[81] гонваны алыр өчен гашура боткасы[82] рәвешендә сүз җыючылар тарафыннан язылган яхшы вә яман фикерләр, ислам дөньясында вә хәкыйкый гыйлем әһелләре арасында урын таба алмадыкларыннан соң Русия мөселманлары арасына килеп урынлаштылар. Асылсыз вә гыйльми җәһәттән әһәмияте булмаган нәрсәләрнең ватане асыллары Русия мөселманларыдыр. Ошбу җөмләдән булган “ай” низагы бу көндә ничек булса, моннан илле хәтта йөз ел элек шул хәлдә иде. Шуның өчен шул хактагы мәктүбләрне күчерүдә яңа бер файда булыр дип зан итмәдек[83].

Рәсемнәреннән истидлял кылып[84] сахибларының табигатьләре, рухи хәл вә әхлакларыны тану дәгъвасыны кылучылар, хәтта шушы хосусда дөреслеккә исабәт итүчеләр[85] бар. Бу, үзенең әсхабенә махсус бер сәнгатьдер. Бик күп адәмнәр иске язуларны вә иске китапларны яки борын заманда язылган кабер ташларыны, биналарны, үрләр вә крепостьләрне күргән вакытларында мөтәэссир[86] булалар, моңаялар. Музәханәләргә[87] кереп кереп йөрүчеләрдән күпләр,

ихтимал, шушы хәлне мөшаһәдә итә[88] торганнардыр. Мин үзем “Бөгелмә” берлә “Чистай” шәһәрләре арасында булган “үр”ләр берлә шәех Шамил рәсемене күргән вакытларымда әсәрләнәм, фикер дәрьясына гаркъ булам[89]. Иске, хосусан, үзебезнең сәләфләребезнең рәсемнәрене күрү дә күңелләрне уйга төшерәдер. Самит[90] вә сакит[91] адәмнернең сүзләре, үз хәлләрене хикәят итеп сөйләүләре бик мәгънәле вә гыйбрәтледер. Адәм баласы үз кашында мәгъруф[92] булган бер галим яки хөкемдар яхуд мәшһүр бер адәмнең рәсемене күрү берлә дөньяның хәяты сәригыз—зәвал[93] бер хыялдан гыйбарәт икәнлегене хөкем кылырга мәҗбүр буладыр.

Франклар вә соң заман мөселманлары да бер адәмнең тәрҗемәи хәлене язган вакытларында фотограф берлә алынган рәсемне дә куялар. Хәзерендә рәсемнәр, тәрҗемәи хәлләрнең олуг рөкенләреннән[94] санала башлады. Ихтимал, моның әһәмияте киләчәк заманда бигрәк тә артыр. Шуңа күрә безләр дә таба алган рәсемнәрне дә куячакбыз. Ләкин рәсем чыгарту бездә бик соң башланган эш булганлыктан, моннан утыз-кырык елларга кадәр вафат булучыларның рәсемнәрене таба алмадык. Рәсемнәрне аерым кәгазьләргә басдырачакбыз. Өйләрендә, урыннарында рәсем тотудан сакланучы кешеләр монларны алып ташларлар. Моннан исә шул кешеләргә нисбәт берлә китапка кимчелек килмәс.

Бу китап басылып таралганнан соң безгә каршы китерелә торган бәхәсләрнең берничәсе: “Мондый олуг адәм хакында бу рәвештәге хәбәрләрне язмаска вә шушы рәвештәге хосусый эшләрне фаш итмәскә тиешле иде”, – диюдән гыйбарәт булачакдыр. Шуның өчен ошбу сөаль[95] микъдар җавапларының берене хәзердән ошбу урында язамын:

Бер милләтнең иҗтимагый хәлләрене төзәтү тугрысында шул милләтнең олуг адәмнәре сәбәп булсалар, бозылуына да сәбәпче шунлар буладыр. “Идел баштан болгана” диелгән мәкальнең мәгънәсе ошбудыр. Иҗтимагый хәлләрнең, гомуми халыкларның төзәлүенә югары сыйныфтан күреп тә бозылуыны түбән сыйныфтан күрү һәм хаксызлык һәм золымдыр. Шан[96] вә шөһрәттән мәхрүм адәмдә булган холык бозыклыгы мисал тотылмас вә үзеннән башка кешеләргә күп күчмәс. Әмма “олуг” дип зан ителгән[97] бер адәмнең әхлаксызлыгы, тәрбиясезлеге бөтен мөхиткә сираять итәр[98] вә күп вакытта күп кешеләр шунларга “гали табигать” вә “һиммәт”[99] дип исем бирәләр, мисал вә гыйбарә кылып йөртәләр.

Шәкерт вакытыбызда бер вилаять зурлыгы кадәр даирәдә булган мөселманнар ике ишан нөфүзенә[100] табигъ будылар[101]. Әүвәлдән бер тугма вә бер—беренә хәер хаһ булып яшәүче ошбу мөселманнар шәехләре арасында тамыр җәйгән мөхасәдә[102] вә мөбагазә[103] корбаны булдылар. Араларына камил мәгънәсе берлә дошманлык урынлашты. Бер—бере берлә кыз алышып бирешмәс вә гадәттән тыш зарурәт иҗбар итмәсә[104], хәяткә ләзем мөгамәләләрне дә кылмас булдылар. Намазларда бер—беренә оемау күрелде. Беренең мөриде күп булса, икенчесенең шәкерте гыйлем вә холык бабында ни кадәр өстен булса да, рухани хезмәтләр өчен мөҗәррәд[105] “чит тарикъ[106]” сүзе берлә җәрех ителер[107] вә кабул күрелмәс иде. Шушындый хәлләр өчен фөкара[108] вә гавам халыклар, җаһил сыйныфлар гаепле булачаклар вә җавап тотылачакларммы?

Бу бер. Икенче сүзебез шулдыр ки: Ибне Хәҗҗәр Гаскалани вә Зәһәби кебек затлар, үзләреннән мөкаддәм[109] килгән галимнәрне интикад[110] итәләр вә хосусый хәлләренә кадәр мөдахәлә кылалар[111], монлар мисал булырга ярасалар кирәк. Исламнарда вә бигрәк тә мөхәддисләр[112] арасында кабул ителгән “җәрех вә тәгъдил[113]” исемле фәннең мәүзугасе галимнәрен интикад кылудан гыйбарәттер. Бу сүзебез өчен безгә: “Син кайда да Ибне Хәҗҗәр кайда?” диләр. Безнең дә бу кешеләргә каршы: “Ибне Хәҗҗәр берлә Зәһәби галимнәре кайда да безнең галимнәр кайда?” дияргә хакыбыз булыр.

“Асар”да язылган адәмнәрнең һәрбере хакында да: “Әдәбият мөәссисләре[114] вә милләт рөкенләре һәм дә бихак дин хамиләре[115] вә инсаният хадимләре[116]” яки “милләтнең рөкенләре вә җитди сурәттә гыйлем әһелләре иде” дәгъвасында түгелбез. Ташны алтын итеп күрсәтү хыялында булмаганлыгыбызны ошбу китапның дибаҗәсендә[117] игълям кылган[118] идек. Өч—биш данәләре истисна ителсә[119], калганнары, ихтимал ки, гадәти кешеләр генә саналырга тиешле булырлар. Шулай булса да, милләт вә кавемемез өчен шунларның да күпме—азмы хезмәтләре булуы вә иҗтимагый хәлләребезгә тәэсир ителүе инкарь ителмәс.

Кыйммәтле бер бинаның мәйданга килүендәге фәзыйләт[120] архитекторларга вә нәфис сәнгатьләрне эшләүчеләргә гаид булса да, күкрәк берлә нигез казучылар вә гадәти ташчы-

ларның хезмәтләре дә бөтенләй игътибарсыз калырга ярамаса кирәк.

Безнең мәкъсудыбыз үзебез тапкан кадәр милләт вә дин хадимләрене язып калдырмактыр. Әмма аларның хезмәтләрене үлчәп сыйныфларга аермак, яхшылары арасында күрелгән истихкаксызларыны[121] чыгарып ташламак вазифасы хәләфләребез[122] өстендәдер.

Әгәр дә сәләфләребез эчендә Газзали вә Ибне Рөшедләр, Бохари вә Ибне Хәнәбиләр, Ибне Тәймия вә Ибне Гарәбиләр йаход Гете вә Толстойлар зоһур итеп[123] тә хәбәрләре безгә килеп җиткән булса да иде, шунларның тәрҗемәләрене язу тугрысында саранлыкмы итәр идек? Хакларыны вафа итсәк[124], итмәсәк тә, такатебез[125] ирешкән кадәр кадәр үз вазифабызны, әлбәттә, җиренә китерергә тырышыр идек.

Әдәбияттан мәхрүм кавем телсез вә милли тарихы булмаган халык җирсездер. Бу инде бәдиһи[126] нәрсәләрдән санала вә гакыл әһелләре тарафыннан икърар ителә торган бер нәрсәдер. Телсез вә җирсез кавемләрнең бу көнге тәназгы[127] бәка[128] низамына[129] күрә дөньяда яшәргә хаклары юк. Каләм рәфикларыбыздан[130] бәгъзылары әдәбиятыбызны оештырырга хезмәт итсәләр, безнең дә бу әсәребез яки “Асар”ыбыз тарихыбызның бер бабыны[131] тәшкил кылыр вә яхшы китаплар нәшер ителгән вакытларга кадәр үз тарихыбызга мәнбәгъ[132] булу хезмәтене итеп торыр. Таң атканнан соң лампа яндырырга хаҗәт калмаганы кабиленнән камил нәрсәләр дөньяга чыкканнан соң нәкысларына[133] хаҗәт калмаслыгы табигыйдыр.

“Асар”ны тәртип итүебез[134] хакында күп адәмнәр каләм ярдәме иттеләр, иске мәҗмәгъләр[135] вә иске мәктүбләр биреп тордылар, кабер ташларындагы язуларны күчереп җибәрделәр. Монларга тәшәккер итү[136] беренче бурычыбыздыр. Бу затларының исемләрене аерым бер җәдвәлдә[137] зикер итсәк[138] кирәк. Шуның берлә бәрабәр иң күп истифадәбез “Мөстәфадел—әхбар” булды. Моны дибаҗәдә йад кылган[139] булсак та, бу җирдә тәкрар кылырга лөзүм күрдек. Соң адәмнәр хакында “Тәрҗеман” гәзитәсеннән файдаландык.

Һәрхәлдә “Асар”да язылган нәрсәләр хакында Табари вә Ибне—Әсир, Мәсгуди вә Ибне Хәлдун, Фәхри вә Әбел—Фида, Карамзин вә Соловьев кеби олуг тарихчылар; “Вафиятел—әгъйан” вә “Фәвател—вафият”, “Әгани” вә “Мәҗмәгыл—бөлдан”, “Холасател—асар” вә “Силафәтел—гасыр”, “Нәфхәт—тыйб” вә “Силкед—дөрәр” кеби тәраҗим әхвал хакында тәртип ителгән әсәрләрдән файдалану мөйәссәр[140] булмады.

Ошбу өченче җилднең ибтидасе[141] 1219-1874 тарихы рәҗәбеннән башланып иң әүвәл телгә алынган зат шәех Гали Түнтәри хәзрәтләредер. Ләкин аннан мөкаддәм тарихларда вафат булган бәгъзе бер могтәбәр вә “Асар”га язылырга тиешле бәгъзе бер затларның тәрҗемәи хәлләре, әүвәлге ике җилд басылганнан соң мәгълүмебез булды. Шунларны төшереп калдырыга күңелебез риза булмаганлыктан тәрҗемәләрне тәртип итеп әүвәлге җилдләргә “зәйл”[142] рәвешендә ошбу икенче җилднең баш тарафына куйдык. Шәех Гали Түнтәри хәзрәтләре тәрҗемәсеннән соңлар үз урыннарында язылдылар. Вафат тарихлары табылмаган затларның тәхмин[143] берлә генә бер урынга куйдык. Монлар бик аздыр.

Гомум өчен әһәмиятле китап булмаганлыгы өчен “Асар”ның икенче мәртәбә табыг кылыну ихтималы юк. Бәгъзы бер фиркаләр өчен генә кирәкле булган әсәрләр бездә түгел, хәтта мәдәни вә бай кавемнәрдә дә аз басылыр вә табгылары яңартылмас.

Оренбург “Асаре кадимә” җәмгыяте (Архивный комиссия) тарафыннан нәшер ителгән китаплар, иң мөһим вакыйгаларны мөштәмил[144] вә тарих гыйлеменә мәнбәгъ булганнары хәлдә икенче дәфга[145] басылганнары юк. Ошбу елда рәсемнәр берлә зур кыйтгада 332 биттә бер тарихи китапны 300 нөсхә генә басдырганлыгы мәгълүм булды.

Күп китә торган китапларның нөсхәләре күп булу нисбәтендә хаклары очсызланган хәлдә, аз китәчәк әсәрләрнең нөсхәләре күп булган саен хаклары күтәрелгәне игътибар ителәдер. Моны һәрбер матбагачы вә китапчы беләдер. Ошбу сәбәптән без бу китапны аз басдырырга карар бирдек.

Бәгъзе вакытта “ихтималы да юк” дип игътикад ителгән[146] нәрсәләр ихтимал гына түгел, хәтта бил—фигыль[147] та булып куялар. Ошбуңа күрә, әгәр дә киләчәк көннәрдә тәкрар басылырга тугры килсә, моны өстләренә алучы затлар ошбу нәрсәләргә ригаять[148] итсеннәр иде:

1. Вакытында беленмәү яки хәтердән чыгу сәбәпле үзләренең тиешле елларыннан соңга калдырып, урыннарыннан кичектерелеп язылган тәрҗемәи хәлләрне, үзләренең тиешле урын-

ларына күчерелсеннәр иде.

2. Тарихлары куелмаган тәрҗемәи хәлләр ияләренең тарихлары мәгълүм булса, шуны арттырсыннар һәм дә шул елның вә аның үзенә ирештерсеннәр иде. Ошбу ике сурәттә тәрҗемәи хәлләрнең тәртипләре үзгәрү лязим килер. Ләкин зарар юк, рәкымнар[149] үзгәрсә үзгәрер, әмма һәркемнең тәрҗемәи хәле үзенең тиешле урынында булыр.

3. Әүвәлге җилд (беренче җөзьэдән башкасы, чөнки бу җөзьэ Казанда университет матбагасыннан алынмый калды) үземнең кульязмаларымнан күчерелсен вә кызыл кара берлә бозылган гыйбарә вә җөмләләр дә китапка керсенннәр иде. Габбаси хәлифәләр заманында бер вәзир: “Әй, Кум шәһәренең казые, без сине урыныңнан төшердек, син тор”[150] рәвешендә сәҗгылы[151] бер җөмлә сөйләү касды берлә Кум шәһәрендәге казыйны газәл итүе[152] кабиленнән[153] безнең әсәрләребез дә низам вә әдәпкә хилаф нәрсәләр булмаганы хәлдә мөҗәррәд бер икътидар[154] күрсәтү өчен мәшьүм[155] бер каләм тарафыннан бозылганнар иде.

4. Беренче вә икенче җилдләр басылып таралганнан соң табылган мәгълүматны язып, тиешле урынларга илхак итеп[156] бардым (монлар хәзер дә аерым бер катыргы эчендәләр, әмма язма нөсхәләргә урынлаштырачакмын). Китап озаюыннан курыкмый шул нәрсәләр китапның эченә керсеннәр иде.

5. “Рәсме хатымны[157], имлямны, тел һәм дә гыйбарәмнең тәртипләрене үзгәртмәсеннәр иде” димим. Хаҗәт булса, монлар үзгәртелерләр. Әмма гарәби калимәләрдәге мөһмәл[158] вә мөгҗәмәләрдә[159] тәсаррыф[160] ителмәсен вә, гомумән, мәгънәләр вә мәзмуннәрне[161] үзгәртү хакында ашыкмасыннар иде. Бер рәкымны дөрестләү хакында биш—алты урынга заказной хатлар язып соралган, җавап маркалары җибәрелгән маддәләрем[162] күп булды. Халыклар тәбдиле һава кылып[163] һәм тәфәррреҗ итеп[164] йөргән вакытларда мин кирәкле кешеләрнең рәсме хатларыны вә яки бер мәсьәлә хакында фикерләрене өйрәнү максаты берлә Оренбург Духовный Собраниясенең иске эшләрене тикшерәдер, бер адәмнең вафат тарихыны табар өчен хисапсыз метрикалар актарадыр, өст-башым, киемнәрем машина берлә ашлык сугучылар рәвешендә тузанга буяладыр, сәгатьләр берлә шул тузан эчендә утырадар идем. Шуның өчен бу хезмәтләремнең җиңел генә эштән чыгуына вә икенче берәүнең шунларга хуҗа булып китүенә риза буласым килми.

Хөрмәтле хәләфләребез, нисйун вә мәнсийун булган[165], дөньяга килмәгән вә җир йөзендә тормаган рәвешенә кергән бер хәкыйрьнең[166] шушы кадәр илтимас[167] вә өмидләрене инша Алла урынына китерерләр.

Инде Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә тәвәккел итеп[168], ошбу көннән табгысына[169] керештек. Хәерле сәгатьтә булсын!

Ризаэддин бине Фәхреддин.

1911-1329 шәһре рәбигыл-әүвәл (10 нчы февраль). Оренбург.

Гыйлавә[170]

Ошбу нөсхәне басдырыр өчен хәзерләп куйганыбызда ошбу сәнә 12 нче февраль шимбә көнгә каршы төн сәгать 1дә фатирыбызга полиция вә жандармлар килеп, губернский жандармский начальник әмере буенча тентү ясадылар вә шул вакытта бу “Асар” нөсхәләрен дә тәмам[171] алып киттеләр. Бастырыр өчен дип карз[172] алган акчаларны шуннан соң сахибларына[173] кире кайтардым. “Асар” нөсхәләре вә башка кәгазьләрем Оренбург жандармский мәэмүрләре[174] тарафыннан Сарапул шәһәрендәге жандармскийга җибәрелгән вә аннан да Казан шәһәрендә окружной суд хозурындагы тәфтишчегә[175] юлланган. Үземнең гаризаларым сәбәпле, бер сәнә тәмам булганнан соң, 1912 сәнә 17 нче февральдә Оренбург полициясе аркылы “Асар” нөсхәсене кайтарып алдым исә дә, күп китапларым, мөсәүвәдәләрем[176], мәкаләләрем, тарихи мәгълүматлар кайтарылмадылар.

Шуның өчен бу китапның кайчан табыг ителәчәге һәмишә[177] мәгълүм түгел.

Ризаэддин бин Фәхреддин.

Оренбург.

1912 сәнә 20 нче февраль.

Россия фәннәр академиясе Уфа фәнни үзәгенең фәнни архивы. Ф.7. Тасв.1. Эш 13 (иске акт).

Асар
Дүртенче җилд
Сүзне башлау

“Асар”ны тәмамы берлә басдыруны үзебез арзу кылган[178] булсак та, матди җәһәттән икътидарыбыз булмаганлыктан бу арзуыбыз җиренә килмәде. Икътидарлары булган затлар арасында бастырып таратуны теләүче күрелмәде вә шул сәбәптән бер өлеше бөтенләй басылмый вә таралмый калды.

Оребургта әсәрләребезне вә мәкаләләребезне мөсәүвәдәләрдән күчереп хәреф җыялар вә аз гына да шикаять итмиләр иде. Хәреф җыючыларга уңай булсын өчен басылачак нәрсәләребезне кәгазьләрнең бер генә ягына вә тарау кәгазьләргә язадыр идек. Шул гадәткә муафикъ[179] “Асар”ны да тарау кәгазьләргә язган идек. Ләкин бер—беренә ныгытылмаган тарау кәгазьләрне тиешле урыннарда саклап тору, саташтырмау вә югалтмау читен, шул сәбәптән дә шунларны бер урынга җыю фикеренә килдем вә гамәлгә дә куйдым (күчердем дә яздым, өченче җилд булды).

Мәгәр дә күп вә озын  мәүзугъләрне[180] китап рәвешендә итеп җыю өчен форсатның иркен булуы вә язу әсбабының җитешлеге зарур икәнлеге мәгълүм. Иртә кичкә сәламәт җитүенә вә кичәдә дә иртәгә сәламәт керүенә ышанычы булмаган кешеләрдә нинди форсат булсын? Кәгазь барында кара юк, кара булганда кәгазь юк, кешедә язу әсбабы җитеш булу ничек сурәтләнсен?

Шуның өчен мөсәүвәдәдә булган адәмнәрне чүпләп вә сайлап кына яздым вә кодрәтем җиткән заманда бертөрле тәмам кылу өчен бәгъзы бер тәрҗемәи хәлләрне кирәгеннән артык кыскартып язуга мәҗбүр булдым.

Һәрхәлдә өченче җилд тәмам булды. Шуннан соң төшергән кыйсемдәге[181] бәгъзе бер хәлләрне хәзеф итүем[182] өчен үкенергә башладым. Шуның өчен төшереп калдырган затлардан бәгъзе берләрене вә хәзеф иткән мәүзугъләрдан да бәгъзе бер җөмләләрне ошбу дүртенче җилдтә күчерергә башладым. Максатыма барып җитәрменме, юкмы?

Бу эш Аллаһы Тәгаләнең үзенә тапшырылган. Бәндәнең вазифасы хәрәкәтләнү вә кәсеп итү булып, тәуфикъ вә морадыны бирү Алладан.

“Асар”ны башлап язарга керешкән вакытымдагы әмәлләрем вә өмидләрем берлә бу көнге әхвал вә әмре вакыйг[183] арасында булган тәзадде[184] вә мөбаянәтне[185] тәгъриф итүгә икътидарым юк. Шул вакыттагы өмидем җир берлә күк арасында сыймас дәрәҗәсендә олуг булган. Шул өмиднең мөҗәррәд бер хыялдан гыйбарәт икәнлекне соң вакытымда үз күзем берлә күрдем. Дөрест, бу көндә дә бер өмидем бар. Ләкин бу өмид элек заманда булган өмидкә бөтенләй башка бер нәрсә.

Бу көн инде “Асар”ны бер кеше укымаслыкны беләм. Язып вә күчереп утыруларым бездән соңлар укырлар рәвешендә бер фикер берлә түгел, динсез латин кавеме өчен төркләрнең – бу мәмләкәттә мөнкариз[186] төркләр вә мөселманнарның әсәрләрене укуга ихтияҗлары вә ләззәтләнүләре булмаслыгы мәгълүм. Бәлки минем күчереп вә язып утыруларым башка бер максат өчен.

Инде максатка керешәмен. Бу җилдтә иске вә борынгы заман адәмләре дә, соңгы заманаларның галимнәре вә мәшһүр затлары да булыр.

РФА УФҮ ФА. Ф.7. Тасв.1. Эш 14 (иске акт).

Асар
Сүз башы

Бу көннән утыз ел мөкаддәм бер вакытта “Асар”ны тәртип кылырга керешкән сәгатемдә булган морадыма муафикъ ошбу 1348 ел 1 нче мөхәррәмдә[187] мәзкүр[188] әсәрне икенче мәртәбә тәртип итәргә башладым. Ләкин беренче мәртәбәдә язарга керешкән вакытымда булган хәлем берлә бу көндәге хәлем арасында булган аерымлык мәшрикъ берлә мәгъриб арасында бул-

ган аерымлыктан да ерак.

Беренче мәртәбәдәге хәлем: “*Милләтебез, гафләт*[189] *йокысыннан уянадыр, аякка басадыр, гыйлем вә мәгърифәткә, һөнәр вә сәнагатькә, кәсеп вә тиҗарәткә*[190]*, дөнья көтүгә, хосусән*[191]*, зирагатькә*[192] *сәләтлелеген мәйданга куячак, моның өстенә дә хөсне холыклы*[193] *вә гафиф*[194]*, диндар бер кавем, нәҗип*[195] *затлы бер милләт икәнлегене дөнья халкына күрсәтәчәк: мәдәнияте җәдидә*[196] *нигезене салуда һиммәте галия*[197] *сахибларының хезмәтләренә иштиракь итә*[198]” дип ләззәтле өмидләр берлә рәхәтләнүдән гыйбарәт иде.

Шул вакытта: “Җөзьэ генә булса да, минем дә хезмәтем кушылсын, кырмыскаларның чикерткә ботыны Сөләйман галәйһис-сәламга һәдия[199] итүләренә охшаса охшасын, һәрхәлдә, бу олуг фидакярлекләр арасында үзем кебек зәгыйфь бер хезмәтем дә катнашсын”, – дигән ләззәтле вә рухлы хыяллар вә фаразлар берлә мәшгуль булган идем.

Әмма бу көндәге хәлне бәян итүгә икътидарым юк. Әүвәлдәге фаразларымның бөтенләй киресе вә гакесе[200] килеп чыкканлыкны күзләрем берлә күрдем. Газиз милләтем җан биреп ятканлыгы күз алдымда.

“Ни кайгы! Ни үкенеч! Ни хурлык вә түбәнлек!” [201]

Бу милләт хакында: “Идел, Урал сахраларында төрк кавеме вә ислам динендә булган олуг бер милләт мең елдан артык вакытлар гомер сөргәннәр, мәчетләре вә җамигъләре[202] дәвам иткәннәр, мәшһүр галимнәре вә киң күңелле сахиблары, зур дәүләт әһелләре булган” дип сөйләүчеләр генә булыр дип тә өмидләнмимен. Әгәр дә Аллаһы Тәгалә сәмави[203] бер галямәт[204] җибәреп тәнбиһ кылмаса[205] вә яки берәр мөҗәддәә[206] күндереп, рәсүлүллаһ Саллаллаһу галәйһи вә сәлләм юлыны ихья итдермәсә,[207] яңартмаса, безнең газиз милләтебез һәлак булачак, хәтта тарих китапларына да керә алмый калачак вә тәмам онытылачак, кәәннә ләм йәкүн[208] булачак. Өч йөз еллардан артык мөддәтләр[209] вәхши урысларга, җәббар[210] императорлар вә падишаһларга мөкавәмәт итеп[211] килгән, динләрене вә миллиятьләрене, гореф вә гадәтләрне саклауга җәсарәтләре[212] вә дәртләре җиткән бу газиз кавем үз араларыннан җитешкән рөшедсез[213] малайларга вә һәртөрле исемнәр берлә зоһур иткән тинтәк ерткычларга, елан вә чаяннарга мокабәләдән[214] гаҗиз калдылар вә инкыйраз дәһшәтеннән үзләрене коткарырга көчләре җитмәде. Тыштан һөҗүм итүче дошманга күрә эчтән һөҗүм итүче дошман зарарлырак. Шул сәбәптән Аллаһы Тәгаләнең казасына тәслим булудан[215] башка чаралары юк. Буласы эш булды.

“Хакыйкатьтә без Аллаһыныкы һәм Аллаһыга әйләнеп кайтабыз. Бөтен кешеләр дә, барлык нәрсәләр дә фани, фәкать кодрәтле һәм юмарт Аллаһы Тәгалә генә мәңгелек”. [216]

Бу язуларны кешеләр укысыннар өчен язмыйм. “Асар”ны яңадан тәртип итсәм, бездән соңлар файдалансыннар иде дигән фикер берлә тәртип итмим. Мондый максатларның вә фикерләрнең хәтта зәррәсе[217] дә күңелебездә калмады. Эшләрнең кайсы тарафларга барачагы инде мәгълүм булды. Безнең морадлар тәмам җимерелде, кирпеч өстендә кирпеч калмады. Өмид тәмам өзелде.

“Бәхеткә ничек ирешергә?
Аннан башка кечерәя таулар,
Аннан башка ялан яак һәм акчасыз үләсең,
Кулың да кечкенә, юлың да куркыныч.” [218]

Дөрест, имам Шәфигый Рәхимулланың бу шигырьләре бер эшнең авырлыгыны бәян кылудан гына гыйбарәт булса да вә икенче бер шагыйрь да ошбу шигыре берлә бер кадәр тәслия итәргә[219] сәгый кылса да[220]:

“Әгәр эшләр Тут кебек катлауланса, син аны Аллаһының мәрхәмәте белән хәл итәрсең. Бәлки, бәлки, бәлки; бәлки чуалган төереңне Аллаһы чишәр” [221], – дисә дә, эш бу дәрәҗәләрдән үтте, гаргарә заманалары[222] килеп җитте.

“Безгә дә кыенлыклар, авырлыклар килеп җитте. Йа Раббым, мин авырлыкларны җиңeләйтүче, ә син рәхимлеләрнең иң рәхиме” [223].

Беренче мәртәбәдә “Асар”ны шәүкъ[224] вә зәвык берлә язган булсам, бу дәфгасында инде үземнең сыңган күңелемә вә янган йөрәгемә юаныч табу, мосыйбәт[225] ялкыннарына су бөркү өчен язам. Әүвәлге мәртәбә тәртип итүемдә каләмемне карага манчып язган булсам, бу дәфгасында инде күземнән аккан яшь тамчыларына манчып язам.

Ризаэддин бине Фәхреддин. 1348 ел 1 мөхәррәм. Уфа.

РФА УФҮ ФА. Ф.7. Тасв.1. Эш 4. (яңа акт).

**Искәрмәләр**

1. мәкъсуд — ният, омтылыш
2. ислах итү — үзгәртү, яхшыландыру
3. хосус — очрак
4. тәрәкъкый — алга китү, югарыга ирешү
5. фәрд — аерым зат, шәхес
6. ихаталы булу — киң булу
7. галибиять — җиңү
8. һәбәс — артык
9. хәер хаһ — теләктәш
10. тәгадди кылу — җәберләү
11. гаҗиз — көчсез, зәгыйфь
12. мөстәхикъ — хаклы, лаеклы
13. заһир булу — күренү
14. морад — теләк, максат
15. интикад кылу — тикшерү
16. тәдбир — тиешле чара
17. тәгъриф итү — аңлату
18. маҗара — булган эш
19. мөсави — бертигез
20. сәләф — борынгы
21. мөшаҗәрә — бәхәсләшү
22. касд — максат
23. хасыйл булу — барлыкка килү
24. хадисә — булган хәл, вакыйга
25. гареш — күк түбәсе
26. сатхи — беркатлы
27. тәблигъ — ирештерү
28. мәүзугъ — проблема, тема
29. гая — теләк
30. ригаять итү — кайгырту
31. мөәррих — тарихчы
32. гадаләт — гаделлек
33. мәсьүлият — җаваплылык
34. Өмәви — Өмәвиләр нәселеннән булган (русча – Омейяд)
35. истибдад — һичбер законга буйсынмыйча хөкем итү
36. сәфаһәт — бозыклык
37. гавам — масса, халык
38. мөахәзә кылу — тәнкыйтьләү
39. мөтәфәккир — фикер иясе
40. мөдафәга итү — саклау
41. мәдех — мактау
42. һәвәс итү — теләү
43. мәнакыйбе әүлия — әүлияләрнең абруйлары
44. мәәхәз — чыганак
45. тәраҗим — биографияләр
46. хәварикъ — гадәттән тыш эшләр
47. кәрамәт — могҗиза
48. тәгъбир — юрау
49. рави — сөйләүче
50. гаид булу — бәйләнешле булу
51. нәкыл итү — язу

52. иҗтиһад — тырышлык
53. касдый сурәттә — теләгәнчә
54. ифрат вә тәфрыйт кылу — чамадан тыш арттыру һәм киметү
55. хилаф — каршы
56. тасхих итү — төзәтү
57. кяфи — җитәрлек
58. хөласа — нәтиҗә
59. ифадә итү — аңлату
60. тәхриф итү — үзгәртү
61. тәгайер кылу — алмаштару
62. хәмлә кылу — өскә атылу
63. истифадә итү — файдалану
64. тәрҗих — өстен күрү
65. табыг итү — бастыру
66. матлуб — таләп ителгән
67. гонван — титул, дәрәҗә атамасы
68. ләкаб — кушамат
69. мөстәдрик — төзәтү
70. гатыф — төрләндерү
71. мизан — үлчәү
72. иҗмали — кыскача
73. яхуд — яки
74. ихтисар — кыскарту
75. гайд — гает
76. гадавәт — дошманлык
77. фирка — төркем
78. мәнша — чыганак
79. гадәд — нөсхә
80. мөтәтаффил — паразит, самозванец
81. мөәллиф — язучы
82. гашура боткасы — мөхәррәм аеның унынчы көнендә махсус әзерләнә торган ашамлык
83. зан итү — уйлау
84. истидлял кылу — нәтиҗә чыгару
85. исабәт итү — дөреслеккә ирешү
86. мөтәэссир — тәэсирләнгән
87. мүзәханә - музей
88. мөшаһәдә итү — күреп тору
89. гаркъ булу — бату
90. самит — телсез
91. сакит — сөйләшмәүче
92. мәгъруф — билгеле, танылган
93. сәригыз—зәвал — тиз бетүчән
94. рөкен — өлеш, терәк
95. сөаль — сорау
96. шан — дәрәҗә
97. зан ителү — уйланган, фараз ителгән
98. сираять итү — таралу
99. һиммәт — дәрт
100. нөфүз — авторитет
101. табигъ булу — буйсыну
102. мохасәдә — көнчелек
103. мөбагазә — дошманлашу
104. иҗбар итү — мәҗбүр итү
105. мөҗәррәд — ялгыз

106. тарикъ — юл, ысул
107. җәрех ителү — хурлану
108. фөкара — фәкыйрьләр
109. мөкаддәм — элек
110. интикад — тәнкыйть
111. мөдахәлә кылу — катышу
112. мөхәддис — пәйгамбәр сүзләрен таратучы
113. тәгъдил — гаделлекне кайтару
114. мөәссис — башлап нигез салучы
115. хами — саклаучы
116. хадим — хезмәтче
117. дибаҗә — кереш
118. игълям кылу — белдерү, аңлату
119. истисна итү — аерып алу
120. фәзыйләт — оста
121. истихкаксыз — лаек булмаган
122. хәләф — киләчәк буын
123. зоһур итү — килеп чыгу, барлыкка килү
124. вафа итү — бурычны үтәү
125. такать — көч
126. бәдиһи — билгеле
127. тәназгы — тартышу
128. бәка — яшәү
129. низам - тәртип
130. рәфикъ — иптәш
131. бап - бүлек
132. мәнбәгъ — чыганак
133. нәкыс — җитешсезлек
134. тәртип итү — төзү
135. мәҗмәгъләр — җыентык
136. тәшәккер итү — рәхмәт итү
137. җәдвәл — список
138. зикер итү — телгә алу
139. йад кылу — әйтү
140. мөйәссәр — җиңел
141. ибтида — башлангыч өлеш
142. зәйл — кушымта
143. тәхмин — якынча билгеләү
144. мөштәмил — үз эченә алган
145. дәфга — тапкыр, мәртәбә
146. игътикад кылу — ышану
147. бил—фигыль — чынлап
148. ригаять — игътибар
149. рәкым — сан
150. гарәпчәдән сүзгә—сүз тәрҗемә
151. сәҗгы — рифмалашкан
152. газәл итү — чыгару
153. кабиленнән - төреннән
154. икътидар — көч, куәт
155. мәшьүм — явыз
156. илхак итү — өстәү, кушу
157. рәсме хатымны - язуымны
158. мөһмәл — ноктасыз хәреф
159. мөгъҗәм — нокталы хәреф
160. тәсарруф — үзенчә үзгәртү

161. мәзмун — эчтәлек
162. маддәләр — биредә: китаптагы бүлекләр
163. тәбдиле һава кылу — һава алмаштыру
164. тәфәрреҗ итү — күңел ачып йөрү
165. нисйун вә мәнсийун булган — онытылган
166. хәкыйрь — хурланылган, кадерсез
167. илтимас — үтенү
168. тәвәккел итү — тапшыру
169. табыг — бастыру
170. гыйлавә — өстәмә
171. тәмам — тулысынча
172. карз — бурыч
173. сахиб — ия, хуҗа
174. мәэмүр — чиновник
175. тәфтишче — тикшерүче
176. мөсәүвәдә — каралама
177. һәмишә — әле дә
178. арзу кылу — омтылу, теләү
179. муафикъ — яраклы, туры китерү
180. мәүзугъ — сюжет, тема
181. кыйсем — өлеш
182. хәзеф итү — төшереп калдыру
183. әмре вакыйг — үткән хәлләр
184. тәзадде — каршылык
185. мөбаянәт — аерымлык, туры килмәү
186. мөнкариз — юкка чыккан
187. 1348 ел 1 нче мөхәррәм — 1929 елның 9 нчы июне
188. мәзкүр — югарыда әйтелгән
189. гафләт — ваемсызлык, гамьсезлек
190. тиҗарәт — сәүдә
191. хосусән — аеруча
192. зирагать — игенчелек, хуҗалык эшләре
193. хөсне холыклы — күркәм холыклы
194. гафиф — намуслы
195. нәҗип — затлы
196. мәдәнияте җәдидә — яңа мәдәният
197. һиммәте галия — зур тырышлык
198. иштиракь итү — катнашу
199. һәдия — бүләк
200. гакес — капма-каршы
201. гарәпчәдән тәрҗемә
202. җамигъ — җомга намазы укыла торган зур мәчет
203. сәмави — күкнеке
204. галямәт — билге
205. тәнбиһ кылу — кисәтү
206. мөҗәддәә — яңартучы
207. ихья итү — яңарту
208. кәәннә ләм йәкүн — бер дә булмаган кебек
209. мөддәт — вакыт
210. җәббар — җәберләүче
211. мөкавәмәт итү — каршы тору
212. җәсарәт — батырлык
213. рөшедсез — туры юлдан бармаучы
214. мокабәлә — каршы җавап кайтару
215. тәслим булу — буйсыну

216. гарәпчәдән тәрҗемә
217. зәррә — бертек
218. гарәпчәдән тәрҗемә
219. тәслия итү — юату
220. сәгый кылу — тырышу
221. гарәпчәдән тәрҗемә
222. гаргарә заманалары — ахыр заман
223. гарәпчәдән тәрҗемә
224. шәүкъ — дәрт
225. мосыйбәт — кайгы, хәсрәт